**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Глава**
**Янгасалского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**
ул. Центральная, 1, с.Б.Янгасала, 422832
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 162204588/162201001

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Янасала авыл жирлеге**
**Башлыгы**
Њзђк урам, 1, Яћасала авылы, 422832,
тел. (8277) 3-55-22 факс: (8277) 3-55-22
e-mail:adm@kama-tamagy.gov.tatarstan.ru
ОКПО 93064624 ОГРН 1061672003414
ИНН/КПП 162204588/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**11 ноябрь 2020 ел** **№3**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең Шәпкә авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 25 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлегенең Шәпкә торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2021 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Шәпкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

- Шәпкәдә авыл эчендәге юлларны ремонтлау, чокырлы урыннарга вак таш җәю, таш сатып алу, ташу, таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- җәйге чорда территорияне чабу(килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- корыган агачлар, куакларны кисү, Шәпкә авылы территориясен җыештыру (килешү буенча эшләр өчен түләү).

"ӘЙЕ" “ЮК”

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән игълан итәргә (бастырып чыгарырга) :

ТР, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урамы, 1;

- ТР, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә 10 көн эчендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Кама**
**Тамагы муниципаль районы**
**Олы Кариле авыл җирлеге**
**башлыгы** **И.Х.Шиһабеев**